| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
| 2019 ел, 12 ноябрь | г.Казань | № 1033 |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 21 июль, 522 нче карары белән расланган «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 21 июль, 522 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 11 июнь, 430 нчы; 2016 ел, 9 апрель, 210 нчы; 2016 ел, 21 ноябрь, 857 нче; 2017 ел, 17 февраль, 98 нче; 2017 ел, 19 октябрь, 797 нче; 2018 ел, 6 апрель, 211 нче; 2018 ел, 31 июль, 623 нче; 2018 ел, 3 декабрь, 1076 нчы; 2019 ел, 12 март, 178 нче; 2019 ел, 28 май, 446 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында:

«Еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | Программа чараларын финанслауның гомуми күләме 2 544,5 млн.сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 1 034,3 млн.сум:<br>2014 ел – 20,0 млн.сум;<br>2015 ел – 97,3 млн.сум;<br>2016 ел – 87,1 млн.сум;<br>2017 ел – 231,5 млн.сум;<br>2018 ел – 99,8 млн.сум;<br>2019 ел – 108,9 млн.сум;<br>2020 ел – 50,0 млн.сум;<br>2021 ел – 289,7 млн.сум;<br>2022 ел – 50,0 млн.сум;<br>федераль бюджет акчасы исәбеннән – 372,8 млн.сум:<br>2017 ел – 41,8 млн.сум;<br>2021 ел – 331,0 млн.сум;<br>билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырыла торган муниципаль бюджетлар акчасы исәбеннән – 5,1 млн.сум:<br>2014 ел – 3,3 млн.сум;<br>2015 ел – 1,8 млн.сум;<br>билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырыла торган бюджеттан тыш акча исәбеннән – 1 132,3 млн.сум:<br>2015 ел – 250,0 млн.сум;<br>2016 ел – 779,2 млн.сум;<br>2017 ел – 103,1 млн.сум.<br>Программаны финанслау күләме фараз характерында була һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.<br>Программада Татарстан Республикасы терииториясендә туристлык-рекреация һәм автотуристлык кластерларын төзү күздә тотыла.<br>Чаралар, төзелә торган кластерлар «Россия Федерациясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмын үстерү (2011 – 2018 еллар)» федераль максатчан программасына кертелгән очракта, тормышка ашырылачак.<br>Программа чараларын финанслау күләмнәре кластерларның проект документларын, Татарстан Республикасы бюджеты акчасының капитал салулар планын формалаштырганда тәгаенләнергә тиеш.<br>Федераль бюджет һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»; |

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программа чараларын финанслауның гомуми күләме 2 544,5 млн.сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 1 034,3 млн.сум:

2014 ел – 20,0 млн.сум;

2015 ел – 97,3 млн.сум;

2016 ел – 87,1 млн.сум;

2017 ел – 231,5 млн.сум;

2018 ел – 99,8 млн.сум;

2019 ел – 108,9 млн.сум;

2020 ел – 50,0 млн.сум;

2021 ел – 289,7 млн.сум;

2022 ел – 50,0 млн.сум;

федераль бюджет акчасы исәбеннән – 372,8 млн.сум:

2017 ел – 41,8 млн.сум;

2021 ел – 331,0 млн.сум;

билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырыла торган муниципаль бюджетлар акчасы исәбеннән – 5,1 млн.сум:

2014 ел – 3,3 млн.сум;

2015 ел – 1,8 млн.сум;

билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырыла торган бюджеттан тыш акча исәбеннән – 1 132,3 млн.сум:

2015 ел – 250,0 млн.сум;

2016 ел – 779,2 млн.сум;

2017 ел – 103,1 млн.сум.»;

Программага теркәлгән кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин